Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«Арча җиденче номерлы урта мәктәбе»

# Арча җиденче номерлы урта мәктәбе кысаларында эшләүче тимурчылык юнәлеше

## Автор турында белешмә

Алсинә Фоат кызы мин,
Арчада белем алам.
Туган телем байлыкларын
Күңел түремә салам
Бөек Тукайны тудырган
Данлы Арча ягыннан.
Үз телемә мәхәббәтем -
Әти-әни каныннан
Каенсарда туып үстем,
Күршедә - Яңа Сала.
Гомәр Бәширов авылы
Шулай диеп атала.
Татар теле - ана телем,
Укыйм татар телендә.
Гаиләм татарча сөйләшә,
Яшим татар илендә.
Мин - татармын, туган ягым
Татарстан төбәге.
Горурланып тибә миндә
Татар кызы йөгәге !



Безнең халыкта элек-электән өлкәннәргә хөрмәт һәм ярдәм итү изге эш дип саналган. Тәрбия эшендә дә без моны үзебезнең максатыбыз һәм бурычыбыз итеп саныйбыз. Үзебездән тыш, кече сыйныф укучыларына үрнәк күрсәтеп, шәфкатьлелек,кешелеклелек, миһербанлылык сыйфатлары булдырырга тырышабыз.



Әлеге юнәлеш мәктәбебездә 1989 елдан бирле актив рәвештә эшләп килә.













Тимурчылык эшендә барлык укучылар да  бик теләп катнаша. Һәр сыйныфка шефлык итү өчен ветераннар билгеләнде. Без ветераннарның өйләренә барып, көчебездән килгән кадәр ярдәм итәбез:кышын өй тирәләрен кардан чистартабыз, яз-көз көннәрендә  бакча эшләренә булышабыз.

Шулай ук ветераннарыбызның күнелен иҗади яктан тулыландыру, тиешле дәрәҗә игътибар күрсәтү максатыннан төрле чаралар оештырабыз. Бәйрәмнәрдә мәктәп укучылары тарафыннан ясалган открыткалар, кул эшләнмәләре белән сөендерәбез.



Әлеге юнәлеш нигезендә чал тарихны киләчәк буынга тапшыру алдыбызга куелган максатланың берсе. Тыл һәм хезмәт батырларының өсләреннән узган хис-кичерешләрен, хәтирәләрен, фоторәсемнәрен туплау белән дә эш алып барабыз. Җыелган материаллар музейда һәм мәктәбебезнең интернет сәхифәсендә саклана.













***Тимурчылык эше кысаларында уздырылган чараларның берничәсен үзегезгә дә тәкъдим итәм.***

# Котлау открыткаларын тапшыру.












# Блокада ипие








# Обелискларны чистарту









Сүземне йомгаклап, Тимурчылык юнәлеше һәр оемада булсын иде дип әйтәсем килә. Чөнки өлкән яшьтәге кешеләргә кайвакыт ярдәм генә түгел, ә игътибар да кирәк. Ә иң мөһиме, өлкәннәр белән аралашканда, балалар халкыбызның гореф-гадәтләре турында күп яңалыклар белә, халкыбыз үткән авыр сынауларны, тормыш хштирәләрен үзләре шул юлны үтүчеләр теленнән ишетеп беләләр. Китап, телевизор экраннары белән чагыштырганда, бу алыштыргысыз, әлбәттә. Шулай ук әлеге очрашулар яшь тимурчыларның үз-үзләрен тотышына да зур тәрбияви йогынты ясый

**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**